# Сызлаулы хәтер

**Бөек Ватан сугышы башлануга 80 ел тулды, тик бу афәт китергән яралар әле дә булса төзәлми, онытылмый. Хәзер без тыныч тормышта яшибез. Шуңа да карамастан, төрле илләрдә сугыш уты кабынып ала, ә вәхши бәндәләр тарафыннан террактлар оештырылып, бер гаепсезгә кеше гомерләре өзелә. Бу язмам тыныч тормышта күзәтелгән сугыш хәрәкәтләрендә интернациональ бурычларын үтәгән Уймуж һәм Федорки авылы егетләренә багышлана. Әйе, дөрес аңладың, укучым, сүзем күп аналар каргаган, яшьләребезне харап иткән Әфган сугышы хакында. Бу илдә әле дә булса тынычлык урнашып бетми.**

Уймуж авылы тарих язуларына башлап 1707 елда теркәлә. Егерменче гасырда шаулап- гөрләп торган авыл иде. Бөек Ватан сугышына кадәр ук бу авыда җидееллык мәктәп эшләгән.

Яңа мәктәп “Озанлы баш” тавына менеп утырган иде. Уймужларның борынгы бабалары бу тауларда, сихри урманнарында озан атканнар. Белеп шундый матур исем бирелгән бу тауга.

Мәктәпнең бер ягында Федоркидан килә торган олы юл, икенче ягында сөзәкләнеп түбәнгә төшә торган чишмә буе. Хәйраннар калырлык матурлык анда: төрле чичкәләр, олактан чылтырап аккан тәмле сулы чишмә агып тора. Янәшәдә генә ямь-яшел мәктәп алды, бакчасы.



Мәктәпнең эче якты, шәм кебек сап-сары яңа бүрәнәләр шома итеп такылланган, тәмле чыршы исе аңкып тора. Мин Уймуж мәктәбендә 7 ел (1969 – 1976 еллар) рус теле һәм әдәбияте дәресләрен укыттым. Бүлмәләр биек, якты, коридор киң, иркен чиста һава. Тәнәфесләрдә радиоузелдан матур көйләр яңгырап тора. Тагын бер шушы мәктәпнең якты бүлмәләрендә рәхәтләнеп балалар укытыр идем! Ләкин тарих артка чикми, шул.

Укучыларыбыз 8 нче сыйныфны тәмамлагач, Крыловода рус мәктәбендә укып китәләр иде, Үдик урта мәктәбендә, училище, техникумнарда укыдылар. Аларның һәрберсе үз урынын тапты, матур яши. Аяныч хәл, 2011 елда авылда мәктәп ябылды, бинасы сүтелде. Күпләрнең йөрәге әрнеде, күңелле чаклары шушы мәктәптә үткән кешеләр исәннәр әле. Мәктәпнең матур алма бакчасы да юк инде. Уймуж авылы, Озанлы баш мескенләнеп, ямьсезләнеп калды. Мәктәп урынындагы бушлыкны узып киткәндә күпләрнең күзләренә яшь киләдер, минемчә. Әле дә ярый, авылны җил-давылдан саклап торган, чәчәкләр белән бизәлгән, җиләкләр

белән тулган биек Калмас тау бар биредә. Бу матур тауда җәен җиләк, көзен мәшкә җыя халык. Ә кышын бала-чага тау шуып куана.

## Уймужлылар – кайнар ноктада

..................................................

Мин тырышларның да тырышы, бик акыллы укучым – Илдус Флүр улы Ямалтдинов турында һәм шушы мәктәп парталары арасыннан чыккан сөлектәй егетләр – Әфган ветераннары турында истәлек калдырмакчы булдым. 1980 – 82 гг. - Командир расчёта СПГ-9 Пянджского ДШБ

**Награды**

Орден Красной Звезды, медали.



Ямалтдинов Илдус оногы белән

“Таулар – кыяларны кичәбез без,
Фляга буш. Корсак шулай ук.
Ком шытырдый тешләр арасында
Ач буламы солдат? Солдат – тук!
Бердәнбер юл – алга, солдат өчен
Чигенү юк! Соңгы сулышта
Тәмугыңа барып керәчәк ул,
Ватан кушса әгәр, ил кушса...”
( Николай Киршенко.)

Ватан кушканга, ил кушканга “тәмугъ”ка барып керделәр 18 – 20 яшьлек алтындай егетләребез. Федорки һәм Уймуж авылларының асыл уллары: Батыршин Рифат Әмин улы (1968г.р. – с ноября 1986г по 3авг.1988г в Афганистане), Фазил Гәйфетдин улы Ибрагимов (20 июля 1960г.р.), Арсланов Илшат Гаптрахим улы (1964г.р.), Аптраков Азат Гасим улы, Имайкин Рамил Мәхмүт улы (2008 елның 19 маенда үлде) Аптраков Мөдәрис Закир улы (1965г.р.), Имайкин Илгизәр Наҗмулла улы (1966г.р.), Ямалтдинов Илдус Флүр улы, Рәдиф Тауфикъ улы Имайкин (1966 елгы), Рәмис Нәзи улы Якупов (1963 елгы). Газиз туган җиребезнең матур табигатендә иркәләнеп, якты мәктәбендә матур киләчәк турында гына хыялланып үскән балакайлар көйдергеч эссе климатлы кыя-таулар арасына, үлем авызына кертеләләр. Булачак “Кызыл Йолдыз” ордены кавалеры Илдус Флүр улы армия сафларына Пермь


Имйкин Радиф дусты белән

шәһәрендәге Калинин заводта эшләгәндә алына. Әфган сугышында катнаша. Яуда каты яралана, чит җирдә каны тама. Илгә икенче группа инвалид булып кайта. Илдусның әнисе Ямалтдинова Рәйсә апа Уймуж мәктәбендә башлангыч класс балаларын укытты. Ул аз сүзле, тыйнак ханым кайгысын кешеләргә чәчә торганнардан түгел иде. Армиядән ак чәчле булып кайткан улын күргәч, кайгысыннан аның да чәчләре агарды. Бүген ул мәрхүмә инде... Ә Илдус төшенкелеккә бирелмәде, хәзер дә көр күңелле, зифа буйлы, күркәм ир – ат. Ямалтдиновлар гаиләсендә ике кыз үсте, хәзер Илдус оныкларын тәрбияли.

Ут мәхшәрен кичкән, һәр көн үлем белән йөзгә – йөз очрашкан прапорщик, өлкән механик Рифат Әмин улы "Сугышчан хезмәт өчен" медаленә ия була. Хәер, хәрби бүләкләр аларның һәрберсендә бар ул. Безнең егетләребез ерак җирләргә исем алу өчен түгел, ә Ватанга хезмәткә алынды. Сезнең Әфганнан исән кайтуыгыз үзе зур бәхет. Рәхмәт сезнең барчагызга. Балаларыгызның уңышларына сөенеп, оныклар уйнатып, озак – озак яшәргә язсын сезгә.

Уймуж авылы егете Илгизәр Имайкин Үдик урта мәктәбендә унынчы классны тәмамлагач, классташы Илдус Әбләшев (Үдиктән) белән Пермь авыл хуҗалыгы институтына укырга керәләр. Беренче курстан соң Совет Армиясе сафларына алыналар. Бу ике аерылгысыз дус Әфганстан җирендә дә бергә хезмәт итеп кайталар. Хезмәт итү чорында күп кенә грамоталар, медальләргә лаек булалар. Хәзер Илгизәр Наҗмулла улы – эшмәкәр. Илдус Хәмит улы полициядә участок инспекторы булып эшләде. Моннан биш ел элек вафат булды, урыны оҗмахта булсын.

Уймуждан танылган хәрби зат – Рафикъ Рәхим улы Имайкин (1946 елгы) турында язмыйча мөмкин түгел, ул туган авылында һәм төбәгебездә зур ихтирамга лаек кеше. Әтисе Рәхим абый Бөек Ватан сугышы ветераны, ул хезмәткә 1934 елда чакырыла, 1941 елда сугышка алына һәм яраланып туган авылына кайта. Рафикъ Рәхим улы Уймуж, Үдик мәктәпләреннән соң Ерак Көнчыгышта Благовещенск танк училищесында һәм Мәскәүдә бронетанк гаскәрләре хәрби училищесында укый, 21 яшеннән тормышын хәрби хезмәткә багышлый. 1970 елда якташыбыз инде өлкән лейтенант, хезмәтен Ерак Көнчыгышта, Еврей автоном өлкәсе үзәге Биробиджан шәһәрендә дәвам итә, бу чорда 3 дәрәҗә "Ватанга хезмәт өчен" ордены, "Сугышчан хезмәт өчен" медальләре белән бүләкләнә. Мотоукчы дивизиянең штаб начальнигы булып хезмәт иткәндә Рафикъ Рәхим улы Әфганстанга җибәрелә. Бу вакытта ул 3 дәрәҗә "Йолдыз"ордены һәм бу ил белән чикләрне саклаган өчен 4 медальгә лаек була. Чечен сугышы башланганда якташыбыз хәрби комиссар вазыйфасын башкара, егетләрне сугыш утына озатуны ике айлап тоткарлап (кичектереп) тора – күпме яшь гомерне саклап кала. Аналар исеменнән Сезгә - Рафикъ Рәхим улы – мең рәхмәтләр әйтеп, тазалык-саулык, бәхет телимен. 1987 елдан ул подполковник, 1995 елда полковник званиесендә отставкага чыга. Хәзер якташыбыз Татарстанның Яр-Чаллы шәһәрендә яши, яшьләрне патриотик рухта тәрбияләүгә үзеннән өлеш кертә. Туган авылына кайта, авылдашлары Рафикъ Рәхим улын сөенеп каршы алалар, "Уймуж полковнигы" дип горурланалар.

# Сәясәттән аерылгысысыз рәвештә

..................................................

Әфган батырлары, гомергә төзәлмәс йөрәк ярагызны яңартуым өчен сездән гафу үтенәм. Солдат вазыйфасын намус белән үтәгәнсез, эти-әниләрегезнең йөзенә кызыллык китермәгәнсез, егетләр. Халкыбызга горурлык, балаларыгызга, яшьләргә үрнәк булып калыгыз. Ни өчен кирәк булган бу канкойгыч сугыш?

Әфганстанда үз илләрендә газиз җирләрен яклап көрәшкән халык. 1970 – 1980 елларда капитализм, я социализмны яклаучылар арасында салкын сугыш та бара. Яхшы коралланган фетнәчеләрдән формалаштырган бандалар совет чикләрендәге шәһәрләрне утка тотарга ашкыналар. Хорошо вооруженные бандформирования мятежников устремились к советской границе для обстрела наших приграничных городов. Поэтому Правительством СССР было принято решение о вводе пограничных войск в ДРА.

Бабрак Кармаль җитәкчелегендәге Әфганстан хөкүмәте хәрби восстаниене революция дип игълан итә һәм үзен саклап калу өчен төньяктагы “туганыннан” ашыгыч ярдәм сорый. Генштаб Әфганстанга гаскәр кертүгә башта ук каршы була. Ләкин югарыда утырган түрәләр бу киңәшкә колак салмыйлар. Шуннан соң совет гаскәрләренә Әфганстан җирендә гарнизоннар ясап урнашырга һәм сугыш хәрәкәтләренә кушылудан тыелырга күрсәтмә бирелә. Кызганыч, бу күрсәтмәләр тормышка ашмый.

“Чикләнгән күләмдәге” совет гаскәрләре (егетләнең иң-иңнәре генә сайлап алына) Әфганстанда сугыш хәрәкәтләренә катнаша башлый. Аяусыз, канкойгыч яу эченә кергәнче 18 яшендәге егет тау юлыннан да, комнан йөрергә, автомат тотып йокларга өйрәнә. Солдат ят халыкның гореф – гадәтләрен сакларга, дипломат та булырга тиеш була. Беренче елларда ук совет гаскәрләре Әфганстан җирендә меңәрләп сугышчысын югалта, ун меңләгән солдат яралана. Картаеп, сакауланып беткән, акылы зәгыйфләнә башлаган “маршал” Брежнев канлы яуга өстәмә көчләр кертә.

За 9 лет войны в Афганистане побывало 620 тысяч советских граждан, из них почти 15 тысяч не вернулись домой. Из Пермской области отправились 6 тысяч человек и недосчитались 415 бойцов. Ә күпмесе тән җәрәхәтләре һәм җан газаплары кичереп, гарипләнеп калды икән. Ут мәхшәрен кичкән егерме яшендәге егетләребез чаларды. Исән калганнары да әниләре каршына аларга караганда картрак булып кайтты. Әфган җирендәге бу сугыш 2238 көн – 1979 елның 25 декабереннән алып 1989 елның 15 февраленә кадәр дәвам итә. Армия Әфганнан чыгарылгач, Барда хәрби комиссариатында 200 ветеран исәпкә алына.

“ Чит-ят җирдә киләчәкне раслап,
Башын салды япь-яшь кыю солдат.
Халык хәтереннән һичкем дә
Юа алмас аны, юа алмас.

Укытучы Елена Архипова сүзләре

Ата-аналар да яшәү терәген, җирдә тотып торучысын югалткач, вакытыннан элек бакыйлыкка күчә. Без бүген беркемгә каршы сугышмыйбыз ләбаса, ә солдат каберләре арта тора...

## Солдат тормышы кайда да җиңел түгел

..................................................................................

Җәйге челләләрдә кызулык 85 градуска җиткән кызу Әфганстан. Сиксәненче еллар. Сугыш. Күтәргесез авыр уйлар... Биредә һәр адымда үлем – әҗәл синең белән янәшәдән атлый: һәр кышлакта, һәр сукмакта сине дошман пулясы яки хәнҗәре каршыларга мөмкин.

Задание алуга һәркем үзе белән автомат, дүрт магазин, ике граната, ике ракета, төтен җибәргеч 2 шашка, коры паек белән тулы рюкзак, 25 кг.- лы ПТУРС снаряды ала. Барысы 40-45 кг.авырлыгында йөк. Шуның белән Әфган тауларында кәҗә кебек сикергәләп йөри солдат. (ПТУРС – танкларга каршы ата торган ракета ). Авыр йөк күтәреп, куркыныч сукмаклардан дүртәр км биеклектәге тауларга күтәрелә солдат... Пакистан башкаласы Пешевардан башкисәр отрядлар Әфганстанга җибәрелеп тора. Суеш – кырылыш...Монда вакытның исәбе юк, яшәү белән үлем арасында көрәш бара.

Исән – имин, иркәм, әлегә, дип
Язды иде һәрбер хатында.
Тик язмады гомерен бирәчәген
Туган җире, иле хакына. (Виктор Верстаков)

Әфган ягыннан кыр казлары кайтканда “кыйгак –кыйгак!” дигән тавышларында мәрхүмнәрнең соңгы ачы авазлары яңгырыйдыр сыман. Сугышчан бурычларын соңгы минуткача намус белән үтәгән ять- яшь егетләрне онытырга безнең хакыбыз юк. Сиксәненче еллардагы ил җитәкчеләренең ялгышлыклары бүген сер түгел инде. Әфган батырлары, кулыгызга каләм алып, эчке кичерешләрегезне чишегез, чит-ят җиргә каннары тамган иптәшләрегез турында истәлекләр язып калдырыгыз, тарих дәвам итсен. “Афганское братство” яши, аралашыгыз, ярдәмләшегез. Әрнү – үкенүләрегез төзәлсен инде. Канлы Әфганнан тәмуг газапларын кичереп исән-имин калганыгызга шөкер итик, әфган яулары башка кабатланмасына өметләнеп яшик. Яңа сугышларга юл куймаслык көч өч нигездән – солдатларның үлемсез батырлыгыннан, аналар газабыннан һәм халыкның хәтереннән тора.

Тормыш рәхимсезлеген, гаделсезлеген күреп Әфганстаннан кайткан егетләрнең бергә оешып, аралашып, ярдәмләшеп яшәүләрен хуплыйбыз. Барда районы Әфган сугышы ветераннар комитеты “РФ гражданнарын патриотик тәрбияләү буенча актив эшчәнлеге өчен" почетбилгесе белән бүләкләнде. Сугыш һәм тыныч тормыш арасы – җир белән күк арасы кебек. Кешеләр белән эшләве җиңел түгел, уңышлар телим сезгә, егетләр. Җитәкчегез – Әнәс Мөхәммәтдин улы Мәүликаевка рәхмәтләр әйтик. Һәр елның 15 февралендә сугышчы-интернационалистларны искә алганда, 28 маенда чик сакчылары көнендә батыр, кыю кешеләр очраша. Урамнан матур һәм горур атлап баруларына карап торуы ук күңелле!

Без Бөек Ватан сугышы ветераннары үрнәгендә тәрбияләндек. Әфганстан илебез халкының патриотизмын ныгытты. Совет солдатлары җирле халыкка азык-төлек белән ярдәм күрсәттеләр, Әфган балалары өчен мәктәпләр ачтылар, авруларны дәваладылар. Безнең хәрби җитәкчеләр Әфганстанның революцион гаскәрләре өчен яртыеллык хәрби һәм азык-төлек запаслары калдырып китте.

## Яшьтән өзелгән гомерләр

...........................................

Хатлар, саргая башлаган солдат хатлары. Солдат хатларында – сагыну. Солдат күңеленә тормыш сулышы өрә хатлар, кайтасы көннәргә өметне көчәйтә. КамАЗ берләшмәсеннән озатылган Вячеслав Курочкин Әфганстанга кызу бәрелешләр чорында барып эләгә. Ул үзенең хатларында һәрбер хәлне уен-көлкегә борып җибәрергә, үзенчә якыннарын юатырга тырыша. Славаның 1987 елның 9 ноябрендә язган хаты аның туган җирен, якыннарын никадәр юксынганын күрсәтә: “ Шулхәтле нык сагындым, әйтеп аңлатырлык сүзләр табып булмый. Тик нишлим? Кая гына эләксәң дә, барыбер хезмәт итәргә һәм бу бурычны җиренә җиткереп башкарырга кирәк. Кайтырга ничә көн калганын санап барам. Миңа тагын 324 көн бар әле”. 4 август көнне Вячеслав рейстан исән-имин кайта, соңгы хатын яза, ә 10 августтагы рейста аның гомере өзелә. Хезмәт срогын тәмамларга нибары өч кенә ай калган була.

Ничек кенә итеп басарга соң  
Җандагы бу сыкрау- әрнүләрне?  
Төзәлмәслек яра булып калды  
Әфганстан йөрәкләрдә мәңге. (Андрей Дементьев)

Бу сугышта һәлак булган бардалылар турында берничә сүз. Барда районыннан Әфган сугышында катнашкан ветераннар саны хәзер 51 гә тигез. Ике егетебез – Байавылдан Наиф Исмагыйлов һәм Озын Яланнан Ринат Батыркаевның яшь гомерләре чит җирләрдә өзелде.

Исмагыйлов Наиф Шәррифулла улы 1961 елның 4 декаберендә Пермь өлкәсе Горнозаводск районында дөньяга туа. Озакламый гаилә Байавылга күченә, биредә аның балачагы үтә. Ул музыка белән мавыга, тик үсә төшкәч кызыксынуы үзгәрә. Барда урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, дусты Фәнил Әмиров белән ерак Сургут шәһәренә туганнарына баралар. Биредә ул профтехучилищега укырга керә, электр белән эретеп ябыштыручы белгечлеге алганнан соң, Сургутта газ эшкәртү заводына эшкә урнаша. Аралашучан, шаян бу егет һәрвакыт нишлисен белә, әйләнә-тирәдәгеләргә дә шөгыль эзләп таба – уйлап чыгару осталыгына ия була. Аның ягымлы елмаюы, зур яшел күзләре үзенә тартып тора. Ә якыннары аны чиктән тыш яраталар. 1980 елда Наиф армия сафларына чакырыла. Башта ул Курил утрауларына барып эләгә, чик сакчысы була.”Яхшы хезмәт итәм. Без монда ундүрт кеше генә. Бик тату яшибез, әйтерсең, без бертуганнар. Элек мин “дедовщина” дигән сүздән курка идем, бездә мондый әйбернең эзе дә юк. Барысы да яхшы, киләчәктә ничек итеп искә алырга да белмәссең”,-дип яза бер иптәшенә. Наиф хезмәт иткән часть 1981 елда

Әфганстанга күчерелә. Унбиш ай хезмәт иткәннән соң,1982 елның 20 гыйнварында Мазари- Шәриф янында барган сугышта якташыбызның гомере өзелә. Исмәгыйлов Н.Ш. Байавылда җирләнгән. Һәлак булгач, “Кызыл Йолдыз”ордены белән бүләкләнә.

Әфган җирендә гомере өзелгән икенче егетебез Батыркаев Ринат Рәүхәт улы 1965 елның 22 маенда Пермь шәһәрендә туа. Озын Ялан урта мәктәбендә белем ала. Армиягә Пермь авыл хуҗалыгы институтының икенче курсыннан алына. Ашхабадта сержант мәктәбен узганнан соң 1984 елның маеннан хезмәтен Әфган җирендә подразделение командиры буларак дәвам итә. 1985 елның 28 апрелендә, ягъни Апрель революциясе көнендә, аның подразделениесе җаваплы хәрби задание үти.Юлларны миналардан арындырган вакытта Ринат һәлак була, әмма хәрби бурычын үтәп өлгерә. Ул туган авылында җирләнә. Тау бөркете кебек горур карашыннан көчле рух бөркелә Ринат егетнең. Нинди кызганыч, секунд эчендә хыяллары җимерелгән, өметләре өзелгән асыл егетләребезнең. Исәннәр хәтерендә шундый матур, батыр егет булып сакланырсың, Ринат, мәңгегә.

Озын Ялан мәктәбенең тышкы стенасында Әфган һәм Чечен сугышларында хәрби бурычларын үтәгәндә һәлак булган укучылары Ринат Батыркаевка, Риф Халитовка һәм Эльмир Кариевка мемориаль такталар урнаштырылган. Алар Башкортстан республикасыннан “Яшел беретлар”легендар ансамбле концертларыннан кергән финанс средстволарына эшләнә. Байавылдан Исмәгыйлов Наиф һәм Төнгүк авылыннан Савинов Сирень истәлегенә дә шундый ук мемориаль такталар алып киләләр. СССР һәм Рәсәйнең Бөек Ватан сугышында, Әфганстанда, Төньяк Кавказда һәм башка кайнар нокталарда һәлак булган иң яхшы уллары батырлыгы истәлеген саклау – бу коллективның төп максаты булып тора. Элмә такталарны халыкка тәкъдир иткәч, артистлар Озын Ялан мәдәният һәм ял комплексында концерт белән чыгыш ясадылар.

Солдат гомере – илгә маяк
Нинди кыска гомер...
Егерме яшь!
Җиңү мизгеленә бетте сыеп...
Нигә үлем белән түләргә соң?
Исемеңне тик калдыру өчен
Мәңгелеккә хәтерләргә уеп? (Андрей Дементьев)

Газиз улларын югалткан, кургаш табут кочып үксегән аналарның кешелеклеген югалтмауларына сокланырга гына кала. Чәчәк ата башлауга ук киселгән ничә мең гомер! Күпме канат кайрылган, өметләр сынган. Түзсә дә түзә икән ул йөрәк – аналар йөрәге... Мәңгелеккә халык күңеленә уелып калган Наиф һәм Ринат кебек егетләребезнең батырлыгы яшьләребезгә үрнәк булып калыр...

Дүрт-биш еллар буе халыктан яшереп алып барган нахак, кирәксез сугышта безнең меңәрләгән гүзәл егетләребез әрәм булды. Әсирлеккә эләккән сугышчыларның террористлар борынын ера, колакларын кисеп ала, төрлечә мәсхәрә итеп туйганнан соң гына үтерәләр икән, кайсыларын печеп җибәргәннәр... Дошманнарның бу

ерткычлыклары турында әкренләп хәбәрләр тарала. Бу канкойгыч сугыштан кайтарылган  кургаш табутларны, 20 яшьлек ак чәчле гарипләрне күргән яшь солдат, бу гаделсезлеккә каршы чыга, үзенчә түрәләрдән үч ала. Кеше ышанмастай хәлләр турында солдат  язалмый, хатлар тикшерелгән. Кулда бармаклар да тигез булмаган кебек, солдатлар арасында ачуын кычкырып әйтүчеләр ешая. Союзга кайтыр өчен үз кулларына үзләре атучылар да табыла.

Җир йөзендә унсигез яшьлек тол хатыннар, бер яше дә тулмаган көенчә ятим калган сабыйлар, кургаш табутлар, ять-яшь егетләрнең кабер өсләрендәге һәйкәлләр булмасын өчен ни эшләргә кирәк? Гаскәрләребезне чит-ят илдән чыгаргач та, инде үзебезнең Ватан эчендә әллә ничә "Әфганстан" барлыкка килде. Әрмәнстан һәм Әзербайҗан республикалары чигендә, Донбасста күпме кан коелды. Кичә дус һәм туган булып яшәгән халыклар бүген бер-берсен кырыша башласалар, безне нәрсә көтә?. Безгә башка канлы күз яшьләре белән корбаннар каршы алырга язмасын, Ходаем.



Батыр егетләребез турында сүзне дәвам итик.

Абляшев Илдус 1966 елның 29 маенда Үдик авылында колхозчы гаиләсендә туа. Үдик урта мәктәбендә Уймуж авылы егете Илгизәр белән бергә унынчы классны тәмамлап, Пермь авыл хуҗалыгы институтына укырга керәләр. Алар беренче курсны тәмамлагач, Совет Армиясе сафларына алыналар. Бу ике аерылгысыз дуслар Әфганстан җирендә дә бергә хезмәт итеп кайталар. Хезмәт итү чорында күп кенә грамоталарга, медальләргә лаек булалар.



Әфганнан кайткач Илдус участок милиционеры булып эшләде. (Инде ул бакыйлыкка күчте,урыны җәннәттә булсын.) Өйләнгән, ике бала үстерәләр. Ә Илгизәр Наҗмулла улы – предприниматель, уңышлар телик бу авыр эшендә.

Әфган батырлары, гомергә төзәлмәс йөрәк ярагызны яңартуым өчен Сездән гафу үтенәм. Ут мәхшәрен кичкән, һәркөн үлем белән йөзгә-йөз очрашкан Мөдәрис Закирҗан улы (1965г.р.), Рифат Әмин улы (1968г.р. – прапорщик, старший механик. "Медаль за боевые заслуги".), Илгизәр Наҗмулла улы Имайкин (1966г.р.), Кызыл Йолдыз ордены кавалеры - Илдус Флүр улы (1962г.р.) Сезнең Әфганнан исән

кайтуыгыз үзе зур бәхет. Рәхмәт сезнең барлыгыгызга. Балаларыгызның уңышларына сөенеп, оныклар уйнатып озак-озак яшәргә язсын сезгә.

Әфган батырларының уллары да әтиләре үрнәгендә яшиләр. Например, у Ямиля Хусаинова сын – офицер, служит на Северном Кавказе. У Рафиса Исмагилова – ветеран военных действий в Абхазии, у Радика Имайкина двое сыновей служили в элитных войсках. У каждого есть работа, семья, дети.

Мы все воспитаны на примерах ветеранов Великой Отечественной войны. Афганистан укрепил патриотизм нашего народа. Советские солдаты помогали там бедным продовольствием, для афганских детей открывали школы, лечили больных. Перед уходом наше начальство для революционных войск Афганистана оставило полугодовой запас боеприпасов и продовольствия.

Мужественные, отважные люди встречаются 28 мая – в день пограничных войск. Любо смотреть на них, как красиво гордо шагают они по улицам Перми.

**Батыркаев Ринат Раухатович (22.05.1965 - 28.04.1985)**




Родился в городе Перми. Учился в Бичуринской средней школе. Призван в армию в 1982 году со 2-го курса Пермского сельскохозяйственного института. После сержантской школы в г.Ашхабаде, с мая 1984 года продолжил свою службу в Афганистане в должности командира подразделения.

28 апреля 1985 года, в день праздника Дня Апрельской революции его подразделение выполняло ответственное боевое задание. При разминировании дороги Ринат погиб, но выполнил свое задание.

Похоронен в с. Бичурино Бардымского района.


Тау бөркете кебек горур карашыннан көчле рух бөркелгән Ринат егетнең. Нинди кызганыч, секунд эчендә җимерелгән хыяллары, өзелгән өметләре асыл егетләребезнең. Исәннәр хәтерендә шундый матур, батыр егет булып сакланырсың, Ринат, мәңгегә.

Аллага да, корбан итеп,
Сарык кына чалалар.
Кем бурычын түләр өчен
Корбан булды балалар?
Иртәгә дәме түрәләр
Канлы кодрәт алырлар?

Олуг бурычлар бар, диеп
Тагын кемне чалырлар? (Мидхәт Исламов)

Младший сержант: [Ринат Раухатович Батыркаев] // Звезда.- 1999.- №19 (февр.).- С.2.

## Другие документы и материалы


Трудовая книжка колхозника

РОС №0572245

Фамилия Батыркаев

Имя Ринат

Отчество Раухатович

Дата рождения (число, месяц, год)

Образование среднее (н/среднее, среднее, н/высшее, высшее)

Профессия, специальность

Дата заполнения книжки „30“ июня 1982 г.

Подпись владельца книжки

М. П.

Подпись лица, ответственного за выдачу трудовых книжек (разборчиво)

1


Пролетарии всех стран, соединяйтесь!

ВСЕСОЮЗНЫЙ ЛЕНИНСКИЙ КОММУНИСТИЧЕСКИЙ СОЮЗ МОЛОДЕЖИ


УЧЕТНАЯ КАРТОЧКА ЧЛЕНА ВЛКСМ

№ 66929878

1. Фамилия Батыркаев
Имя Ринат Отчество Раухатович
2. Год и месяц рождения 1965, май
3. Пол мужской 4. Национальность башкир
5. Место рождения г. Пермь (село, район, город) Пермской области (округ, область, край, республика)
6. Социальное положение учащийся (рабочий, колхозник, служащий, учащийся)
7. Образование начальное (начальное, н. среднее, среднее, н. высшее, высшее)
8. Месяц и год вступления в ВЛКСМ апрель 1982
9. Наименование комсомольского органа, утвердившего прием в комсомол Бардымский райком ВЛКСМ Пермской области
10. Месяц и год вступления в КПСС

439

ЦК ВЛКСМ


Характеристика
выпускника Бичуринской средней школы
Батыркаева Рината Раухатовича
родившегося 22 мая 1965 года
в г. Перми, члена ВЛКСМ
В классе выполнял общественное поручение политинформатора. Хорошо разбирается в политике. Умело ведет свою общественную работу.
Член ВЛКСМ с 1982 года с апреля. Он своевременно платит взносы. Ринат сдал ленинский зачет на хорошую оценку.
Всегда участвовал в предметных кружках особенно по математике.
Ринат общителен, разговорчив, так же скромен. С друзьями всегда в хороших отношениях.
К учителям он всегда относился с уважением, не допускает лишних слов.

Директор школы /[illegible]/
Кл. руководитель /Тухтамышева Р.М./
Секретарь комс. орг. /Хамакаева Л./
21.06.82 г.

Мемориальные доски погибшим при исполнении воинского долга в Афганистане и Чечне, выпускникам Бичуринской школы Ринату Батыркаеву, Элмиру Кариеву и Рифу Халитову.

Мемориальные доски были изготовлены на средства, вырученные от концертов легендарного ансамбля «Зеленые береты» из Республики Башкортостан. Такие же доски они привезли и в память Сиреня Савинова из села Тюндюки и Наифа Исмагилова из деревни Куземьярово. Основной целью этого коллектива является сохранение памяти о подвигах лучших сынов СССР и России, воевавших и погибших в ВОв, в Афганистане, на Северном Кавказе и других горячих точках. После открытия артисты выступили с концертом на сцене Бичуринского КДК.

Мемориальные доски установили на внешней стене школы.



## Исмагилов Наиф Шарифович (04.12.1961 - 20.01.1982)



Наиф родился в Горнозаводском районе. Детство прошло в деревне Куземьярово, куда вскоре переехала его семья. В детстве увлекался музыкой, но в юности его увлечения изменились. Окончив Бардымскую среднюю школу, он с другом Фанилем Амировым поехали к родственникам в далекий город Сургут. Там он поступил в Сургутское профтехучилище на специальность «электросварщик», окончив учебу, пошел работать на Сургутский газоперерабатывающий завод. Этот общительный, веселый парень всегда мог найти, чем занять себя и окружающих, был невероятным выдумщиком. Его обаятельная улыбка и большие зеленые глаза буквально притягивали к себе людей. А близкие его просто обожали.

В октябре 1980 года его призвали в армию. Наиф попал на Курильские острова, пограничником. «Служу хорошо. Нас всего 14 человек. Живем очень дружно, как родные братья. Раньше я все время боялся слова «дедовщина», у нас здесь такого вообще нет. Все хорошо, даже потом вспоминать, наверное, будет нечего», - писал Наиф своему другу. В Афганистан военная часть, где служил Наиф, была переведена в 1981 году. Прослужив чуть больше 15 месяцев, 20 января 1982 года Наиф погиб в бою под Мазари-Шарифом. Похоронен в д. Куземьярово Бардымского района.

Библиография

Илькаева, С. Их имена не забудутся / С.Илькаева // Рассвет.- 1988.- 1 мая.- С.4.

**Награды**

Орден Красной Звезды (посмертно)






**Другие документы и материалы**







СРОЧНАЯ ТЕЛЕГРАММА

МИНИСТЕРСТВО СВЯЗИ СССР

ПРИЕМ: 23 06 98 го — час. — мин.

Бл. № 745

Принял:

ПЕРЕДАЧА: — го — ч. — м.

№ связи

Передал:

= НЕ УКАЗАНИЕМ НР ГОС ПМК СГПЗ БЫЛА НА СПРАВКЕ ПМК СГПЗ СРОЧНАЯ ГОРОД СУРГУТ УЛИЦА 6 ЛИНИЯ ДОМ 27 ИСМАГИЛОВОЙ АЛЬФИЕ АХМАТЗИЕВНЕ=

СР ТЕРМЕЗ 6901 39 22 14


Служебные отметки:

КОМАНДИРОВАНИЕ ЧАСТИ ИЗВЕЩАЕТ ЧТО 20 ЯНВАРЯ ПРИ ВЫПОЛНЕНИИ СЛУЖЕБНЫХ ОБЯЗАННОСТЕЙ ПОГИБ ВАШ СЫН НАИФ СРОЧНГО ТЕЛЕГРАФИРУЙТЕ СОГЛАСИЕ НА ОТПРАВКУ ТЕЛА СЫНА ПО МЕСТУ ВАШЕГО ЖИТЕЛЬСТВА=КОМАНДИР ЧАСТИ=

60297

Лом. т., з. 550.

Исмагилов Наиф Шарифуллович // Оставшиеся молодыми…: памяти павших участников боевых действий посвящается.- Сургут, 2006.



ИСМАГИЛОВ
Наиф Шарифуллович
4 декабря 1960 года

3 года

6 лет

17 лет

В сургутском ПТУ № 17, а также в школе, где учился Наиф Исмагилов установлены мемориальные доски. Один из классов носит его имя. К сожалению, обстоятельства гибели Наифа остаются до сих пор невыясненными. Известно лишь, что погиб он в кровопролитном бою близ афганского города Музавир-Шериф.

Наиф родился 4 декабря 1960 года в поселке Теплая гора Горнозаводского района Пермской области. Детство Наифа прошло в деревне Куземьярово Бардымского района, куда вскоре переехала его семья. Именно здесь 1 сентября 1968 года Наиф переступил порог школы.

Он рос шустрым, но отзывчивым и внимательным ребенком, всегда был рад помочь маме, Альфие Ахметвиевне, по дому. Да это и не удивительно, в деревне дело всегда найдется, даже для маленького мальчика: и воды принести нужно, и пол вымыть, и мусор вынести. Эта привычка к труду не осталась в прошлом и тогда, когда в 1977 году вся семья Исмагиловых переехала в Сургут.

Еще в детстве Наиф увлекался музыкой: учился играть на гармони и даже на саксофоне. Но в юности его интересы и увлечения очень изменились, и он поступил в ПТУ №17 на специальность «Электросварщик». И в школе, и в училище Наифа запомнили как старательного и усидчивого ученика. Как говорится, звезд с неба не хватал, но бездельником и хулиганом никогда не был, так что Альфие Ахметвиевне не приходилось краснеть за сына. Окончив училище, Наиф устроился работать по своей специальности на Сургутский газоперерабатывающий завод.

СОДРУЖЕСТВО

Но не учеба и не работа больше всего привлекали юношу. Важнее всего для него было общение, налаживание теплых, дружеских отношений в семье, в компании сверстников, на работе. И это удавалось Наифу великолепно благодаря душевному теплу, исходившему от этого молодого человека, его отзывчивости, вниманию к людям. К тому же с ним никогда не было скучно. Этот общительный, веселый парень всегда мог найти, чем занять себя и окружающих, был невероятным выдумщиком. Его обаятельная улыбка и большие зеленые глаза буквально притягивали к себе людей. Поэтому и неудивительно, что у Наифа было множество друзей, приятелей и просто знакомых, а мама, сестра и брат его просто обожали. Альфия Ахметвиевна часто ловила себя на мысли: «Для кого-то он будет идеальным мужем». Но судьба распорядилась иначе…

14 октября 1980 года Наиф был призван в армию. Свой курс молодого бойца он прошел в Хабаровске. Оттуда в составе подразделения пограничных войск был направлен на Курильские острова. В Афганистан военная часть, где служил Наиф, была переведена в 1981году. Прослужив чуть больше 15 месяцев в Афганистане, младший сержант Исмагилов Наиф Шарифуллович погиб в бою. Это произошло 20 января 1982 года в городе Музавир-Шериф.

СОДРУЖЕСТВО




Солдат гомере – илгә маяк
Нинди кыска гомер... Егерме яшь!
Җиңү мизгеленә бетте сыеп...
Нигә үлем белән түләргә соң
Исемеңне тик калдыру өчен
Мәңгелеккә хәтерләргә уеп?... (Андрей Дементьев)

Газиз улларын югалткан, кургаш табут кочып үксегән аналарның кешелеклелеген югалтмауларына сокланырга гына кала. Чәчәк ата башлауга ук киселгән ничә мең гомер! Күпме канат каерылган, өмет сынган. Түзсә түзә икән ул йөрәк – аналар йөрәге... Мәңгелеккә халык хәтеренә уелып калган Наиф һәм Ринат кебек батыр егетләр яшьләребезгә үрнәк булып калырлар. Илләр тыныч булсын, күкләр аяз булсын!

Интернациональ бурыч

Ярдәм сорап күп килделәр безгә
Барысына да бу ил булышты...
Тик беләсе иде –

Без соң тагын
Кайсы илгә күпме бурычлы?
“Интернациональ бурыч”, дидек,
Әллә нәрсә итеп сөйләдек.
Бурычтырмы... –
Нигә меңәрләгән
Кеше җаны белән түләдек?!
Япь- яшь кенә килеш күпме гарип –
Аналарның йөрәк түземме?
Бурыч түләр өчен егетләрнең
Аяк-кулы кирәк идеме?!
Илдә нигә кадерсезләнделәр,
“Бурыч” түләде бит алар да? –
Ахыр чиктә йөрәкләре нигә
Граната булып ярыла?!
“Интернациональ бурыч”, имеш,
Табалмадык шуннан башканы.
Ил “бурычы” булып,
Әсирлектә
Газап чигә кемнең башлары?!
....... Тагын кемгә күпме “бурыч”лы без,
Нигә белми халык?
Бүгенге
Яңа буын егетләре үсә –
“Бурыч” түләр өчен түгелме?! (Харрас Әюп)

## Уймуж полковнигы



Рафик Рәхим улы Имайкин (1946г.р.) турында язмыйча мөмкин түгел, ул туган авылында зур ихтирамга лаек кеше. Әтисе-Рәхим абый - Бөек Ватан сугышы ветераны. Ул 1934 елны хезмәткә чакырыла, ә 1941 елны сугышка алына. 1945 елны каты яраланып, аксак булып Уймужга кайта.

Рафик Рәхим улы Уймуж, Үдик мәктәпләрен тәмамлый. Училищедан соң заволта эшли. 21 яшеннән хәрби хезмәттә була. В 1967 году окончил военное училище, учил молодых танкистов. В 1970 году он – старший

лейтенант. Служил на Дальнем Востоке и  в Биробиджане ЕАО.

Когда служил начальником штаба мотострелковой дивизии, его отправили в Афганистан. Афганистанда хезмәт иткәндә ике хәрби орден белән бүләкләнә. 1987 елны Рафик Рәхим улына полковник исеме бирелә. 1995 елда гына полковник отставкага чыга. Чаллы шәһәрендә Автозавод районының хәрби комиссары булып эшли. Когда началась Чеченская война, он был военным комиссаром. Два месяца удерживал парней от отпрвки в самое пекло войны. От имени родителей солдат говорим вам огромное спасибо за отсрочку введения войск в военные действия.

Ул бүген дә сафта, яшьләрне патриотик рухта тәрбияләүгә үзеннән өлеш кертә. Туган авылы Уймужга еш кайта һәм авылдашлары Рафик Рәхим улын сөенеп каршы алалар. “Уймужның полковнигы” дип, горурланып искә алалар Имайкин Рафик Рәхим улын.



Файма Мубарак кызы Газизова, Барда, 2022